Республика Татарстан
Новоимянское сельское
поселение Сармановского
муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль
районының Яңа Имән
авыл җирлеге

**РЕШЕНИЕ**
21 август 2017 ел

**КАРАР**
**№ 16**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Сарман муниципаль районының «Яңа Имән авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4.3 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында»2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен гамәлгә ашыру максатларында, шулай ук Россия Федерациясе Президентының «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указының 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге Советы
Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына «Яңа Имән авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү тәртибен расларга.
2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Яңа Имән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Яңа Имән авыл җирлеге
Советы рәисе Р.Ф.Гараев